| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br><br>**СОВЕТ ЧИСТОПОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА** | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br><br>**ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ** |
|---|---|---|

***Решение*** ***Карар***

**2019 елның 20 нче ноябре** **Чистай шәһәре** **№ 49/1**

Җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен башкарганда барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында, Чистай муниципаль районының “Чистай шәһәре” муниципаль берәмлеге һәм Чистай муниципаль районы авыл җирлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы “Чистай муниципаль районы” муниципаль берәмлеге бюджетыннан субсидияләр бирү хакында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 142.3 статьясы нигезендә Чистай муниципаль районы Советы

Карар бирә:

1. Чистай муниципаль районы «Чистай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге бюджетыннан субсидияләр Чистай муниципаль районы «Чистай шәһәре» муниципаль берәмлеге бюджетына һәм Чистай муниципаль районының авыл җирлекләре бюджетларына (алга таба - җирлек) җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча Чистай муниципаль районы җирлекләренең җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен үтәгәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында (алга таба - субсидияләр) түбәндәге очракларда бирелә:

- башка дәрәҗәдәге хакимият органнары карарлары кабул ителгән очракта чыгымнарны компенсацияләүгә акча бирү;

- җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл иткәндә барлыкка килә торган вакытлы касса өзеклекләрен каплауга акчалар бирү;

- Чистай муниципаль районы бюджетының өстәмә керемнәре, шулай ук Чистай муниципаль районы бюджетының калган өлешендә агымдагы финанс ел башына акчалар бирү;

- башка очракларда, гамәлдәге законнар нигезендә өстәмә чыгымнар

барлыкка килү.

2. Субсидияләр, күрсәтелгән максатларга киләсе үзгәрешләрне исәпкә алып, чираттагы финанс елына Чистай муниципаль районы Советы карарында каралган бюджет ассигнованиеләре һәм бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә бирелә.

3. Чистай муниципаль районының Финанс – бюджет палатасы әлеге карар нигезендә бирелә торган бюджет ассигнованиеләрен төп бүлүче булып тора.

4. Чистай муниципаль районы җирлекләре бюджетларына субсидияләрне бүлү, алдагы үзгәрешләрне исәпкә алып, Чистай муниципаль районы Советының «Чистай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге бюджеты турында карары белән раслана.

5. Субсидияләр бирү максатлары һәм шартлары Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты һәм җирлекләрнең башкарма комитетлары арасында әлеге килешүләр нигезендә билгеләнә

6. Килешүдә түбәндәге төп нигезләмәләр булырга тиеш:

а) субсидияләрнең максатчан билгеләнеше;

б) субсидия бирү һәм аны тоту шартлары;

в) субсидия бирүгә каралган бюджет ассигнованиеләре күләме;

г) субсидия күчерү графигы;

д) субсидия бирү һәм тоту өчен билгеләнгән шартларның үтәлешен тикшереп тору тәртибе;

е) финанс тәэминаты чыганагы субсидия булган чыгымнарны тормышка ашыру турында хисап бирү сроклары һәм тәртибе.

7. Килешү проектын әзерләү Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан башкарыла.

8. Килешү проекты Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан җирлеккә җибәрелә.

9. Килешү Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе һәм авыл җирлеге башлыгы (Башкарма комитет җитәкчесе) тарафыннан имзалана.

10. Субсидия алу өчен, килешүдә билгеләнгән вакытта, җирлек Чистай муниципаль районы Башкарма комитетына Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан билгеләнгән документларны тапшыра.

11. Җирлекләр бюджетларына бирелә торган субсидия күләме Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан билгеләнгән формула буенча билгеләнә.

12. Субсидияләр Татарстан Республикасы буенча Федераль казначылык идарәсенең территориаль органнары счетларына җирлекләр бюджетларына күчерелә, алар - килешүдә билгеләнә торган срокларда җирле бюджетлар башкаруына касса хезмәте күрсәтү өчен ачыла.

13. Субсидияләр бирү шартлары бозылган очракта, тиешле акчалар Россия Федерациясенең бюджет законнарында билгеләнгән тәртиптә муниципаль район бюджеты кеременә күчерелергә тиеш.

14. Субсидияләр бирү елыннан соң килүче елның 1 гыйнварына файдаланылмаган субсидияләрнең калган өлеше Россия Федерациясе Бюджет

кодексында билгеләнгән таләпләр нигезендә «Чистай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге бюджеты кеременә кайтарылырга тиеш.

15. Субсидияләрдән максатчан файдалануны тикшереп торуны Чистай муниципаль районы башкарма комитеты һәм Чистай муниципаль районының бюджет палатасы законнар нигезендә гамәлгә ашыра.

Чистай муниципаль районы
Башлыгы Д.А. Иванов